**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Зур Фролово авыл җирлегенең Каенлык авылында гражданнар җыены карары**

12 ноябрь 2024 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Зур Фролово авыл җирлегенең Каенлык авылында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2025 елда Зур Фролово авыл җирлегенең Каенлык авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия балигъ булган гражданнарның һәркайсыннан 500 сум күләмендә үзара салым җыюны кертергә.

2. Җыелган акчаны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итүгә

-Каенлык авылындагы торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны ремонтлау) өчен юнәлдерергә.

3. Җыен нәтиҗәләрен Зур Фролово авыл җирлегенең Каенлык авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Зур Фролово авыл җирлеге башлыгы _________ М.С.Кудряшова

Халык җыены секретаре _________ В.А. Антипова